СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
15.12.2015

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№ 42

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Иҗтимагый советы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р. Н. Миңнехановның 2015 елның 27 августындагы ПР-263 номерлы III Республика социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар форумы йомгаклары буенча күрсәтмәләре исемлегенең 7 пунктын үтәү йөзеннән, Зеленодолськ муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. 2014 елның 21 февралендәге 363 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән (2015 елның 05 мартындагы 497 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - Нигезләмә) расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый советы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Иҗтимагый совет составына элегрәк Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль хезмәт вазыйфаларын, җирле үзидарә органнарында сайланулы вазыйфаларны Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән береннән артмаган санда керергә мөмкин.»;

2) 3.3 пунктында:

2.1) «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт вазыйфаларын» сүзләренә алмаштырырга;

2.2) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В.Тыгин**